# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Майна авыл җирлеге Чуваш Майнасы авыл торак пунктында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**2023 елның 12 октябреннән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 12 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2024 елда Алексеевск муниципаль районының «Майна авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге территориясендәге Чуваш Майнасы авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

1) кышкы һәм җәйге чорда юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) торак пунктта урамнарны яктыртуны карап тоту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

3) торак пункт юлларын төзекләндерү (юлларга таш түшәү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) җирләү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

5) су башнясы өчен су насосы сатып алу;

6) каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнер мәйданчыгы урнаштыру (төзелеш материалы алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

7) ДПОны ремонтлау.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 297 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 153 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 153 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлегендәге Чуваш Майнасы авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез 2024 елда Алексеевск муниципаль районының «Майна авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Чуваш Майнасы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

1) кышкы һәм җәйге чорда юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) торак пунктта урамнарны яктыртуны карап тоту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

3) торак пункт юлларын төзекләндерү (юлларга таш түшәү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) җирләү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

5) су башнясы өчен су насосы сатып алу;

6) каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнер мәйданчыгы урнаштыру (төзелеш материалы алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

7) ДПОны ремонтлау.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен ,Майна авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә,Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Майна авыл җирлеге башлыгы Я.Д.Иванов